- Бай сүзлек запаслы булу белән бәйле рәвештә туган тел һәм әдәбиятыннан белемнең дәрәҗәсе югары.
- Тарихи материалларны тирән анализлап халык авыз иҗаты өлкәсендә эзләнү эшләре алып бару.
- Алган белемнәрне олимпиада, конкурс, иҗади проектларда куллана алу.
- Алган белемнәрне файдаланып Туган телләр елына багышланган “Әбием сандыгы” проектының сценариесен төзү, җәмәгатьчелекне җәлеп итү.
- Проектның диск вариантын шәһәр мәктәпләренә тарату.

Проектның киләчәк үсеш перспективалары колачлы булыр, чөнки милли йолаларын, телен яхшы белгән, аңа хөрмәт, ярату белән караган кеше генә шәхес булып формалаша ала. Тарихын белмәгәннең киләчәге дә юк. Проект шуларны яшь буынга аңлату юнәлешендә төзелде. Җәмәгатьчелекне җәлеп итү әти - әниләребездән башланып китсә, шәһәребездә яшәүче милләттәшләребезне дә кызыксындыруны, киләчәктә шушы юнәлештә форум оештыруны максат итеп куям.

***Александрова Алсу Исмәгыйль кызы,***
*27 нче мәктәпнеңюгары категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы,*
*Бөтенроссия “Туган тел” мастер-класс бәйгесе призеры,*



Татар телендә белем бирүнең сыйфатын арттыруны стимуллаштыруга, мәктәп укучылары белән эшне оештыруга инновацион алымнар таратуга, талантлы укытучыларга ярдәм итүгә, шулай ук туган телдә укытуның нәтиҗәле педагогик тәҗрибәсен таратуга педагоглар өчен үткәрелгән грантлар зур этәргеч бирә. Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елыуңаеннан Татарстан Мәгарифһәм фән министрлыгы татар телендә укыта торган педагоглар өчен грантка бәйге игълан итте. 27 нче урта мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучысы Александрова Алсу Исмәгыйль кызы бу бәйгегә Google

Classroom платформасында татар телен өйрәнү, укучыларның интеллектуаль һәм иҗади потенциалын гамәлгә ашыру өчен мәйданчык булдыру проектын тәкъдим итте. Соңгы вакытта барлык фәннәр буенча да, шул исәптән татар теле һәм әдәбиятыннан да, мәгълүмати ресурслар саны артты. Татар теле дәресләрендә цифрлы белем бирү ресурсларын куллану укучыларда уку, язу күнекмәләрен формалаштыру һәм үстерү, кирәкле материал табу, укучыларның сүзлек запасын баету, татар телен өйрәнүгә мотив формалаштыру кебек бурычларны үтәргә мөмкинлек бирде. Болар – күп очракта татар телен мөстәкыйль рәвештә өйрәнер өчен булдырылган проектлар. Татар теле һәм әдәбияты курсы өчен  эчтәлек ягыннан сыйфатлы, балалар өчен кызыклы, заманча технологияләрне кулланып ясалган электрон платформалар әлегә юк.Бу проблема дистанцион уку вакытында бигрәк тә кискен чагылды. Күпчелек укытучыларга татар теле дәресләрен WhatsApp мессенджеры ярдәмендә үткәрергә туры килде. Бүгенге көнә татар телендә белем бирүче, балалар белән аралашу, белемнәрен тикшерү мөмкинлеге булган  интернет мәйданчык булдыру иң әһәмиятле бурычларның берсе.

Google Classroom платформасында татар теле һәм әдәбиятын, мәдәниятен  өйрәнү максатыннан интернет мәйданчык булдыру – укучылар, әти-әниләр, укытучылар һәм мәгариф учреждениеләре өчен бик актуаль проект.

Уку елы дәвамында бу проект нигезендә Google Classroom платформасында “Фәнсөяр” мәйданчыгы булдырылды. 9 нчы сыйныф укучылары бу мәйданчыкта татар теле буенча интерактив күнегүләр, онлайн викториналар эшләделәр, ребус, кроссвордлар чиштеләр, интернет челтәре проектларын төзеделәр. “Фәнсөяр” мәйданчыгы укучыларның мөстәкыйль эшләү күнекмәләрен үстерергә, алдынгы мәгълүмати технологияләр белән эшләү осталыгын арттырырга; татар телен, әдәбиятын һәм мәдәниятен өйрәнүгә кызыксынуларын көчәйтергә ярдәм итте. Бу проектның эш нәтиҗәсе Мәгариф министрлыгы сайтына урнаштырылды.

Проектная работа: интернет площадка (платформа) «Фәнсөяр»:
https://disk.yandex.ru/d/TMu3GGr4Qd9-HQ

## БӨТЕНРОССИЯ “ТУГАН ТЕЛ” МАСТЕР-КЛАСС БӘЙГЕСЕ



**2021 нче елның 22–24 март** көннәрендә Казан шәһәренә илебезнең 48 төбәгеннән Ана теле (рус, татар, чуваш, мари, удмурт) укытучылары Бөтенроссия мастер-класс бәйгесендә көч сынашырга җыелдылар. Татарстан Республикасыннан, Россия регионнарыннан (Төмән, Ульян, Пенза, Омск, Әстерхан, Свердлау, Оренбург, Красноярск өлкәләреннән һәм Башкортостан, Удмуртия, Чувашстан, Мордовия Республикаларыннан) катнаштылар. Бу мәртәбәле бәйге 3 турдан торды. Беренче читтән торып башкарылган турда укытучылар зур сынау үттеләр. Видеодәрес, укучыларның һәм укытучының эш нәтиҗәләрен күрсәткән портфолио профессиональ жюри тикшерүләрен узды.Бәйгенең читтән торып этабында республика районнарыннан 78 мөгаллим һәм ил төбәкләреннән 17 туган (татар) тел һәм әдәбияты укытучысы катнашты. Йомгаклау этабына 50 туган тел һәм әдәбият укытучысы, шул исәптән 17 татар теле укытучысы, 10 рус теле, 6 чуаш, 4 мари, 2 мордва теле укытучылыры һәм Россия субъектларыннан 10 туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы узган. Алар арасында шәһәребезнең 27 нче урта мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучысы Александрова Алсу Исмәгыйль кызы да бар иде.

Бәйгенең беренче көнендә һәр укытучы үзенең эш тәҗрибәсендә актив кулланылып килгән метод, алым, технологияләрне тәкъдим итте. Мастер-класста укытучының һөнәри осталыгы, сөйләм техникасы, аудитория белән эшләү дәрәҗәсе игътибар үзәгендә булды. Алсу Исмәгыйль кызы иҗади фикер йөртү технологиясенә нигезләнгән “Фикерләр өйрәтмә, фикерләргә өйрәт” дигән темага бик кызыклы, мавыктыргыч мастер-класс тәкъдим итте.

Икенче көнне һәрбер конкурсант “Мәдәниятләр диалогы” дигән темага проект күрсәтеп, үзләренең алдынгы тәҗрибәләре белән уртаклаштылар. Алсу Исмәгыйль кызы комиссия алдында “Мәдәниятләр диалогы музее” проектын яклап чыкты. Толерантлы шәхес тәрбияләүдә, төрле милләт балаларының аралашу культурасын формалаштыруда музейларның роле бик зур. Музейлар - кешелек дөньясы, халык, милләт хәтере генә түгел. Алар -

укучыларны тәрбияләү, аларга педагогик тәэсир итү чарасы да. Алсу Исмәгыйль кызы үзенең проектында шуларны ассызыклап үтте.

Өченче турда конкурсантлар түгәрәк өстәл янында әңгәмә үткәрделәр. Комиссия биргән сорауларга җавап бирделәр, туган телне үстерү, укучыларны кызыксындыру юлларын барладылар.



Дулкынланып, өметләнеп көткән конкурсның бүләкләү тантанасы Казан шәһәренең **Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясендә** үтте. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Илсур Гәрәй улы Хадиуллин бәйрәмне ачып җибәрде. Үзенең чыгышында ана теленең роле, аны үстерү, саклау турында сөйләде. Бөтенроссия бәйгесендә катнашкан укытучылар бер-бер артлы сәхнәгә чакырылдылар.Аларга дипломнар, истәлекле бүләкләр, чәчәк бәйләмнәре тапшырдылар. Һәм, ниһаять, 50 катнашучы арасыннан 2 нче призлы урын яулаган Түбән Кама шәһәре 27 нче урта мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучысы Алсу Исмәгыйль кызы Александрова бүләкләнде.

**Мастер-класс**

**Тема:** “Фикерләр өйрәтмә, фикерләргә өйрәт.

**Максат:** Укытучыларның һөнәри үсешенә шартлар булдыру; татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә иҗади фикерләү технологиясенең алымнары белән таныштыру, әлеге алымнарны практик кулланырга өйрәтү.

**Кулланылган технология:** Иҗади фикерләү технологиясе.

**Алымнар:** “Сәйлән җыю” уены, Шед системасы, “Үстерешле канун”, “Киләсе хәреф”алымнары.

**Үткәрү формасы:** Мастер-класс.

**Җиһазлау:** Компьютер, проектор, презентация, плакат, картиналар, кәгазь битләре, маркерлар.

**Мастер-класс барышы.**

**I. Оештыру, мастер-класс эшчәнлегенә мотивация булдыру. Мастер-классның максатын билгеләү.**

- Исәнмесез, хөрмәтле хезмәттәшләрем! Мин сезне барыгызны да мастер-класста күрүемә бик шатмын. Мастер-классны “Фикерләр” мультфильмнан өзек карау белән башлап җибәрәсем килә.

- Мультфильмда нинди фикерләр турында сүз барды?

Көтелгән җавап: акыллы, мәрхәмәтле, шаян, усал, сәер фикерләр.

- Традицион укытуда нинди фикерләрне үстерү өстендә эшли идек?

Көтелгән җавап: акыллы, мәрхәмәтле фикерләр.

- Ә кайсы фикергә игътибар җитми ?

Көтелгән җавап: сәер фикергә.

- Ә ни өчен аны сәер фикер дип атаганнар, нинди фикер соң ул?

Көтелгән җавап: эзли, йөри, бер урында гына тормый.

- Димәк, традицион дәресләрдә укучыларны тынгысызламыйча гына,проблемалар тудырмыйча гына укытучы, әзер материалны бирә. Укучылар аны кабул.итә. Репродуктив фикер йөртүен үстерә. Ә бүген яңа стандартлар нигезендә без укучыларга әзер материал бирергә тиеш түгел. Укучы аны үзе эзләп табарга тиеш. Мондый эшчәнлек эзләнү эшчәнлеге дип йөртелә. Эзләнүнең асылы нидән гыйбарәт соң? Укучы нәрсә эзли? Ул үзендә туган сорауга җавап, килеп чыккан проблеманы хәл итү ысулын эзли. Фикри эзләнү - катлаулы процесс. Эзләнүләр продуктив һәм иҗади фикер йөртү күнекмәләрен үстерә, фикерләргә өйрәтә.

Мастер классның темасы: “Фикерләр өйрәтмә, фикерләргә өйрәт” (Иммануил Кант).

Укучыларның эзләнү эшчәнлеге аша продуктив һәм иҗади фикер йөртү күнекмәләрен ничек үстерергә? Нинди технология, метод һәм алымнар бу максатка ирешергә мөмкинлек бирә.

Проблемалы, үстерешле укыту технологияләрен мисалга китерер идем. Бу технологияләрдә бик күп алымнар, эш төрләре һәм уеннар бар. Мин бүген сезгә иҗади фикерләү сәләтен үстерүгә ярдәм итүче берничә уен, алым тәкъдим итәм.

**II. Төп өлеш**

Татар әдәбияты дәресе. Укучылар әсәр белән таныш түгел, ә авторы турында алдагы сыйнфыларда мәгълүмат бирелгән.

**1. Фокус төркем белән эш**

Фокус төркемгә әсәр исемен, авторның туу һәм вафат булган елларын, автор туган республика һәм районны ачыкларга кирәк булачак.

**1 төркемгә** авторның туу һәм вафат булган елларын, автор туган республика һәм районны ачыкларга Шед системасы ярдәм итәчәк.

**Шед системасы-даталарны истә калдыру яисә табу өчен кулланылан торган система.Махсус фраза яки сүздәге хәрефләр саны истә калдырасы, табасы дата белән туры килергә тиеш.**

Мәсәлән, Клеопатраның туган елын истә калдыру өчен "царица-красавица" фразасы ярдәм итә. ("царица" сүзендә 6 хәреф, "красавица" сүзендә - 9).

Димәк, Клеопатра безнең эрага кадәр 69 нчы елда туган.

Сезгә махсус ике җөмлә бирелә, сүзләрдәге хәрефләр саны ярдәмендә тиешле даталарны табарсыз, ә җөмләләр авторның туган җиренә ишарә ясый.

**Бирем:**

**1930- Ә Татарстан бай республика**

**1995- Ә педагогия училищесы көчле**

**-2 төркемгә** әсәр исемен ачыкларга 3 төрле алым ярдәм итәр.

**“Үстерешле канун” алымы**

Өч сүз бирелә, беренче ике сүз икенче баганадагы сүзләр белән билгеле бер мөнәсәбәттә тора. Өченче сүзгә дә шундый мөнәсәбәттә торган сүз табарга кирәк.

Мәсәлән,

ХӘРЕФ - И

ҖӨМЛӘ КИСӘГЕ-ИЯ

СҮЗ ТӨРКЕМЕ - ?

**Бирем:**

| | |
|---|---|
| хайван | **төлкеләр** |
| агач | **тирәкләр** |
| кош | ? |

**“Киләсе хәреф” алымы**

Сүздәге һәрбер хәрефне алфавитта үзеннән соң килгән хәреф белән алмаштырып язу.(Түгәрәк буенча “я” хәрефе “а” белән алыштырыла)

**Бирем:**

СОЧЙАМ-ТӨШКӘН

**“Тартмалар” алымы (темница)**

| | | |
|---|---|---|
| **ж** | **к** | **д** |
| **а** | **и** | **ү** |
| **ә** | **с** | **р** |

Һәр хәреф бер тартмада урнашкан, шуның формасына карап бирелгән код ярдәмендә хәрефләрне табарга

**Бирем:** 

**2. ЗАЛ белән эш**

Мин сезгә “Сәйлән җыю” уенын тәкъдим итәм. Сәйлән- вак пыяла төймәчекләр. Шул төймәчекләрне җыеп муенсага, калфакка тезү өчен матур-матур бизәкләр, сәнгать әсәрләре тудыралар. Бу процесс уен шикелле җиңел, шул ук вакытта иҗади да. Бу уенда да кечкенә генә кисәкләрне, өлешләрне берәм-берәм җыеп бер мәгънә, төшенчә китереп чыгарырга тиешбез.

- Хөрмәтле коллегалар! Сезнең каршыгызда картина. Аның үзәгендә без ир-атны күрәбез, аның кулында китап. Ләкин йөзе дә, кулындагы китап исеме дә безгә билгеле түгел. Димәк, без язучының һәм әсәрнең исемен ачыкларга тиешбез.

- Картина нинди дә булса мәгълүмат бирәме? Безгә аны сәйлән бөртекләре шикелле берәм-берәм җыярга кирәк.

- Язучының яшәгән чорын ачыйклыйбыз.Бу язучы турында сез барыгызда беләсез, ә кайберләрегезнең аны күргәне дә бардыр. Мәгълүмат кысылды.

Көтелгән җавап: 20нче гасыр урталары 21нче гасыр башлары.

- Язучының кайсы яктан, төбәктән икәнлеген әйтә алмасак та, республикасын әйтергә була.Сез моны кайдан белдегез?

Көтелгән җавап: картинада Казан кремле сурәтләнгән.

**1 нче рәсем.** Казан кремленә игътибар итегез әле. Бүгенге Казан кремле белән картинадагы кремль арасында нинди аерма бар? Ни өчен?

Көтелгән җавап: картинада Кол Шәриф мәчете юк. Димәк, автор 2005 нче елга кадәр вафат булган. Кол Шәриф мәчете рәсми төстә 2005 елның 24 июнендә Казан меңьеллыгына ачыла.

**2 нче рәсем.** Журнал, такта, акбур.

Көтелгән җавап: укытучы әсбаплары.

- Димәк, язучы булудан тыш укытучы булган.

**3 нче рәсем.** Диңгез, флот, баш киеме.

Көтелгән җавап: хәрби флотта хезмәт иткән.

**4 нче рәсем**. Казан Дәүләт университеты.

Көтелгән җавап: Казан Дәүләт университетында укучы , бәлки укытучы булган.

5 нче рәсем. Авыл рәсеме.

Көтелгән җавап: иҗатында төп тема- авыл темасы.

- Авторны атый аласызмы?

Көтелгән җавап: Мөхәммәт Мәһдиев.

**6 нчы рәсем (өстәмә).** Мәчет. Иж-Бубый мәдрәсәсе турында беренчеләрдән булып Мөхәммәт Мәһдиев күтәреп чыга. Хезмәтләр яза.

**7 нче рәсем (өстәмә).** Дүрт тополь.

Үзенең истәлекләрендә Мөхәммәт ага болай дип язган: “Йорт өчен урын сайлаганда, эти, үзенең күршесе Гыйбадулла карт белән сөйләшеп, аның ындырын алган һәм чирек гектарлы урында бакча ясаган. Шул ындырга ул иң башта дүрт тополь утырткан. Ул топольләр хәзер бик юан һәм бик җәенке. Әни барлыгы тугыз бала тапкан. Бишесе үлгән. Аларның кабере дә билгесез. Безнең гаиләдән бары тик дүрт кеше үсеп дөньяга чыкты. Мин хәзер уйлап куям: эти нигә инде тугыз яки ун тополь утыртмады икән?”

**III. Рефлексия**

- Эзләнү эшчәнлеге нәрсәгә китерде?

Көтелгән җавап: продуктив һәм иҗади фикер йөртү күнекмәләрен үстерә.

- Эзләнү, иҗади фикер йөртү нәрсәгә кирәк икән соң ул?

“Фикерләр” мультфильмының дәвамын карау.

- Әйе, сәер фикерләр булганда, ягъни эзләнүле эшчәнлек вакытында гына яңа ачышлар уйлап табыла.

***Пузикова Ольга Сергеевна,***
*учитель русского языка и литературы высшей квалификационной категории МБОУ «Гимназия №32» НМР РТ, лауреат Всероссийского конкурса мастер-классов учителей родного языка и литературы «Туган тел» в 2021 году*



Пузикова Ольга Сергеевна, учитель русского языка и литературы высшей квалификационной категории МБОУ «Гимназия №32» НМР РТ, лауреат Всероссийского конкурса мастер-классов учителей родного языка и литературы «Туган тел» в 2021 г., победитель республиканского конкурса

грантовой поддержки профессионального роста учителей общеобразовательных организаций Республики Татарстан в номинации «Учитель-наставник» в 2019 году.

Ольга Сергеевна – творческий учитель, обладающий высоким уровнем педагогического мастерства, находящийся в постоянном поиске новых методов обучения. Учитель активно осваивает современные технологии, успешно применяя их в урочной и внеурочной деятельности. Большое внимание педагог уделяет работе с одаренными детьми. За последние три года Ольга Сергеевна подготовила 7 победителей и 14 призеров муниципальных предметных олимпиад по русскому языку и литературе, 36 победителей и призёров научно-практических конференций муниципального и республиканского уровня. Её выпускники показывают высокие результаты на экзаменах, средний балл ЕГЭ по русскому языку в 2021 году составил 80,8 балла, 17 учеников получили от 84 до 98 баллов.

Ольга Сергеевна – человек высокой культуры, занимающий гуманистическую позицию по отношению к обучающимся. Её отличают искренняя заинтересованность в результатах своего труда, высокая эрудиция и отличное знание особенностей преподавания русского языка и литературы. Работая над внедрением технологии индивидуального стиля в учебной и внеурочной деятельности, она эффективно использует авторскую программу по работе с творчески одаренными детьми. Обладая высоким профессионализмом, высокими организаторскими способностями, педагог решает задачи создания в классах микроклимата, способствующего повышенной мотивации ребенка к учебе. Учитель успешно решает проблему информационной уплотненности программ повышенной трудности через поиск новых путей в развитии мышления и эмоциональной сферы ребенка.

Имея необходимый опыт работы и отличные знания по предмету, Ольга Сергеевна является старшим экспертом региональной предметной комиссии по русскому языку и литературе по проверке заданий ЕГЭ и ОГЭ с развернутым ответом. Накопленным опытом педагог активно делится с коллегами, проводя мастер-классы на республиканских и муниципальных конференциях и семинарах. С 2017 года Пузикова О.С. руководит муниципальным методическим объединением учителей русского языка и литературы Нижнекамского муниципального района РТ.

***Ильгузина Людмила Петровна,***
*учитель чувашского языка и литературы первой квалификационной категории МБОУ «Гимназия-интернат №34» НМР РТ, участник Всероссийского конкурса мастер-классов учителей родного языка и литературы «Туган тел» в 2021 году*



**МАСТЕР-КЛАСС**

Добрый день, уважаемое жюри, коллеги.

Ырӑ кун, пурне те!

Ман пата кам хастар – ҫавсене тухма ыйтатӑп. Халӗ эпӗ сире галстуксем салатса паратӑп. Ҫак галстуксем патне эпир каярах ҫаврӑнса ҫитӗпӗр, хальлӗхе галстук тӗсне кура ушкӑнласа ларса сӗнетӗп.

1-мӗш ушкӑн: сирӗн сарӑ тӗслӗ галстуксем. Сарӑ тӗсе - чӑвашсен юратнӑ тӗсӗсӗр пуҫне - хӗвел, ӑшӑ, чӑвашсене ҫутта кӑларакан И.Я.Яковлевпа ҫыхӑнтарӑпӑр.Яковлев калавӗсенче ӑса вӗрентекен вырӑнсене тупмалла. (Пулӑ тытни, ….)

2-мӗш ушкӑн: сирӗн ушкӑнӑн галстукӗсем хӗрлӗ тӗслӗ. Хӗрлӗ - асӑрхануллӑх, вӑрҫӑ тӗсӗпе ҫывӑх. Вӑрҫӑра пур этем те пӗтӗм вӑйне пухса пӗр шухӑшлӑ пулса - тӑшмана хирӗҫ тӑма пултарать. Сирӗн валли ӗҫ-вӑрҫа хутшӑннӑ ҫыравҫӑсемпе поэтсен пултарулӑхӗнче ҫынсем пӗр-пӗрне пулӑшнине кӑтартакан вырӑнсене аса илесси.

3-мӗш ушкӑн: сирӗн ушкӑнӑн паян репортерсем пулса, паянхи ӗҫсене сӑнласа пама пултармалла. Видеоролик, видеосюжет евӗрлӗ материал хатӗрлемелле.

Юлашкинчен икӗ ушкӑн хӑйӗн ӗҫӗсене тӑвать, кайран вара пӗтӗмлетсе доска ҫине ҫыпӑҫтарса хурать.

Ĕçсене пĕтĕмлетнĕ май, манăн сире пĕчĕк притча аса илтерес килет. Пĕр çын хăйĕн вĕрентекенне тĕрĕслесе пăхас тесе юлташне çакна  каланă: манăн ыйту вĕрентекене шухăша ярать! Юлташĕ унпа килĕшмен. Хайхи ирхине хиртен пĕр лĕпĕше тытса килет те ăна аллисенм хушшине курăнмалла мар хурса вĕрентекенне çакăн пек ыйту парать: «Ман алăри япала чĕрĕ е чĕрĕ мар?» Хăй çав вăхăтра çапла шутлать: «Чĕрĕ тесен – эпĕ лĕпĕше лапчăтса вĕлерĕп, чĕрĕ мар тесен – сывах хăварăп. Çакăн пек эпĕ хамăн вĕрентекенрен ăслăрах пулăп», тесе шутлать. Вĕрентекен çак çыннăн ыйтуне илтсен « Веçех санăн аллунта!» - тесе хуравлать

Хамăрăн мастер-класа флешмоба вĕçлес килет.

Дай пять.






***ЯруллинаГелюсяСаетгараевна,***
*учитель родного языка и литературы  высшей квалификационной категории*
*МБОУ «Лицей №35», победитель муниципального этапа,*
*участник зонального этапа конкурса «Учитель года - 2021»*
*в номинации «Лучший учитель татарского языка и литературы”*



Гелюся Саетгараевна работает над методической темой «Использование на уроках родного языка информационно-коммуникативных технологий как фактор повышения качества образования». Ее отличает пытливый ум, организованность, высокая эрудиция, умение мыслить самостоятельно и творчески, чему она пытается научить своих обучающихся. При 100% успеваемости качество знаний ее обучающихся остается неизменно высоким: по родному языку - 100%, по литературе – 100%.

Гелюся Саетгараевна в течение многих лет участвует в подготовке олимпийского резерва при Центре внешкольной работы с одаренными детьми. Её воспитанники ежегодно прославляют Нижнекамск на республиканской предметной олимпиаде по татарскому языку и литературе (Ахметова Эльвина, ГильмуллинаКамиля, СагитоваСамира). Также ученики Яруллиной Г.С. – победители и призеры всероссийских и республиканских конференций и конкурсов: Всероссийский конкурс научно-исследовательских и творческих работ учащихся “Литературный Татарстан; Республиканская юношеская научно-исследовательская конференция имени С.С. Молодцова; Поволжская юношеская научно-практическая конференция “Я – исследователь; Республиканский конкурс чтецов «Тугантелем – серле тел»; региональная научно-практическая конференция «Школьники – науке XXI века»; Республиканский творческий фестиваль учащихся им. Г. Афзала; Региональная научно-практическая конференция школьников «Тукай укулары» и другие.

Имеющийся у Яруллиной Г.С. опыт позволил ей разработать авторскую образовательную программу национально-регионального компонента “Чулманэнҗеләре” (рецензент: кандидат педагогических наук, зав. кафедрой педагогики и педагогической психологии НФ Казанского инновационного университета Р.Ф. Гатауллина); методическую разработку «Сборник диктантов для 5-8 классов» (утверждена доцентом ТГПУ В.А. Гариповой); методическую разработку в сборнике ресурсного центра по подготовке к олимпиадам по татарскому языку и литературе и др.

Приняла участие в экспериментальной деятельности Всероссийской экспериментально-творческой группы педагогов ЦПИ и РО «Новый век» по теме «Применение инновационных педагогических технологий в урочной и внеурочной деятельности»; ведет инновационную деятельность по теме «Отработка модели сетевого взаимодействия с целью передачи лучших образовательных практик для повышения эффективности деятельности образовательных организаций» при ФГБОУ ВО «НГПУ».

*“Бала – өстенә һәртөрле бизәк төшерү мөмкин*
*булган бәһалы җәүһәр,*
*яки һәрнәрсәне язарга яхшы булган ак кәгазьдер ”*
***Р. Фәхреддин***

## МАСТЕР-КЛАСС.
## МӘГЪЛУМАТ БЕЛӘН ЭШЛӘҮНЕҢ БЕР ЫСУЛЫ БУЛАРАК ХӘТЕР КАРТАСЫ АЛЫМЫН КУЛЛАНУ.

Максат:Укытучыларның һөнәри үсешенә шартлар булдыру; татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә хәтер картасы алымнары белән таныштыру, әлеге алымны практик кулланырга өйрәтү.

Экрандагы рәсемнәрдә сез нәрсәләр күрәсез, аларның охшаш һәм аермалы яклары нәрсәдә?

- *Дискета, флешка, каты диск??*
- *Охшаш яклары: мәгълуматны саклау өчен,*
- *Аермалы яклары: хәтере күләме*

- Әйе, көннән-көн мәгъламут арта, кеше төрле мәгълуматларны истә калдыру өчен төрле җайланмалар, төрле алымнар куллана. Шул алымнарның берсе турында без бүген сезнең белән танышырбыз.

Шулай итеп, минем мастер –классымның темасы:

<u>Мәгълумат белән эшләүнең бер ысулы буларак хәтер картасы алымын куллану</u>

Алымның авторы Британ галиме һәм бизнесмены Тони Бьюзен.

Инглизчә бу алым "mind maps" - майндмэпинг дип атала. «mind» сүзе «акыл» ә «maps» сүзе «карта» дигәнне аңлата. Тәрҗемәсе сез экраннарда күрсәсез.




- Сезгә кайсы тәрҗемә күбрәк ошый?

- Без укучылар белән хәтер картасы дигән тәрҗемәне сайладык, һәм туган тел һәм әдәбияты дәресләрендә бу алымны уку материалларын истә калдыру, хәтергә төшерү, кабатлау максатларыннан кулланабыз.

Хәтер картасы - мәгълүматны кабул итү, эшкәртү һәм истә калдыру процессларын, иҗадилыкны, хәтер һәм фикерләүне үстерү коралы.

- *Дәресләрдә белем алуның стандарт ысуллары*
- *Текст белән эшләшәндә күбрәк нинди ысуллар кулланасыз? Татар теле дәресләрендә, яки математикада күбрәк кагыйдә өйрәнү, таблицалар тутыруга кайтып кала.*

Стандарт ысулларның житешсезлекләре:

Мәгълүматны истә калдыруы кыен.

Бертөрлелек мәгълүматны кабул итү мөмкинленген киметә

*Хәтер картасын ясауның төп шартлары: иҗадилык, төсле карандашлар, маркерлар куллану, сәгать йөрешендә уку....*




Татарстан темасыны хэтер картасы ясау:
1. Төп идея – Татарстан
2. Табигате- елгалары-Идел - Чулман – Агыйдел – Нократ
3. Шәһәрләре- Казан –Иннаполис – Чаллы –Түбән Кама – Әлмәт – Алабуга
4. Тагын нинди мәгълүмат ала алдык?

- Авыл хуҗалыгы турында
- Кара алтын
- Татарстан спорт үзәге, бик күп терле спорт ярышлары Татарстанның башкаласы – Казан шәһәрендә үткәрелә: 2013 ел – Студентлар универсиадасы; 2018 ел - Халыкара футбол уеннары, һ.б. Күптән түгел генә фигуралы шуу буенча Россия ярышлары уздырылды
- Татарстанның төзелеше, сәнәгате
- Болар барсы да Татарстанның үсеше һәм киләчәге

Татарстанның иң зур байлыгы ул – аның күпмиллэтле халкы. Татарстан презеденты Рөстәм Нургалиевич Миннехановның указы буенча, республикабызда 2021 нче ел Туган телләр һәм Халыклар дуслыгы елы дип игълан ителде.




- Татарстанда ничә төрле милләт вәкиле яши? Бу сорау Халыклар бердәмлеге көненә багышланган Бөтенроссия этнографик диктантта да бар иде. (Слайт ) Сан буенча беренче урында – татарлар, икенче руслар, өченче – чувашлар. Ә менә киләсе халык саны исәбен алу ничек күрсәтер? 2021 нче елда Бөтенроссия халык санын исәпләү үткәреләчәк (1 апрель-230 апрель) (2020 елның октябереннән күчерелде)

- Ә хәзер төркемнәрдә хәтер – картасы төзиячәкбез. *(1 төркем татар милләте, 2 төркем-рус милләте) Һәр төркем үз картасын яклый.*

- Бик зур рәхмәт, коллегалар.

- Әйе, хәтер-картасын менә шулай итеп укычылар да үз куллары белән ясый алалар. Ләкин бүгенге көндә укучыларның кулларында төрле гаджетлар, алар мәгълуматны күбрәк интернеттан алалар. Шуңа күрә, укучыларны тагын да кызыксындыру өчен төрле кушымталардан , программаларда файдалана алабыз. Шулардан берсе, бабл.ас кушымтасы (https://bubbl.us/ ) (Слайт )

Яки хмайнд программасы (https://xmind-map.ru/ ) *(Карталар белән таныштыру)*




- Нәтиҗә ясап, хәтер- кратасының уку эшчәнлегендәге ролен әйтеп китегез әле?!

*(Уку сыйфатын яхшырта, үзлектән өйрәнү мөмкинлеген тудыра һ.б.)*

**«Бөек мәгърифәтче Ризаэтдин Фәхретдиннең түбәндәге сүзләре бар: “Алтын булачак бер шәкертне туфрак итеп җирдә калдырган укытучы да һәм туфрак булачак бер баланы алтын итә белгән укытучы да бар”.**

Үзебезнең эшебез, гамәлебез, сүзебез белән, каршыбызда утырган балаларны алтынит алсак иде дигән теләк белән мастер-класымны тәмам итәм. Игътибарыгыз , һәм миңа ярдәмегез өчен бик зур рәхмәт!

***Ахмадиева Рузиля Рафаэловна,***
*учитель татарского языка и литературы первой квалификационной категории*
*МБОУ «Лицей №14» НМР РТ,*
*призер муниципального этапа конкурса «Учитель года - 2021»*
*в номинации «Лучший учитель татарского языка»*



Рузиля Рафаэловна – педагог высокой квалификации. Она является победителем V Всероссийского конкурса профессионального мастерства «Педагогическая статья», победитель конкурса профессионального мастерства «Современный педагог - 2021» в номинации “Лучший мастер-класс”, победитель муниципального конкурса чтецов "Живая классика", победитель III Открытого Регионального фестиваля-конкурса национального татарского искусства "Бәхет йолдызы" в номинации "Художественное слово", лауреат IIстепени премии имени Клары Булатовой в номинации «Литература», призер IX Республиканского консурса молодых писателей "Иделем акчарлагы" в номинации "Драма".

Ахмадиева Р.Р. - грамотный, творчески работающий педагог, понимающий проблемы современной школы, постоянно стремящийся к самообразованию, самосовершенствованию. Ее ученики – победители и призеры муниципального этапа олимпиады по татарскому языку и литературе, победители всероссийского конкурса чтецов «Я говорю стихами о войне…», VIII Открытого Регионального фестиваля-конкурса татарского национального искусства "Бәхет йолдызы", призеры разных конференций.

В области обеспечения информационной основы деятельности Рузиля Рафаэловна использует инновационные технологии в практической деятельности, активно распространяет свой опыт через выступления на семинарах, научно-практических конференциях, форумах различного уровня.

Рузиля Рафаэловна настойчиво добивается поставленной цели. Молодая, целеустремленная, отзывчивая, дисциплинированная, любящая и уважающая детей, видящая в каждом ребенке большой потенциал, пользуется заслуженным авторитетом у обучающихся и педагогов.

Мастер-класс **«Яңа биттән”**



Беләсезме, кичә тормыштагы безгә ишелеп төшкән эмоцияләрдән бераз гына арынып тору максаты белән, үземә бирелгән бүләкләрне карап утырдым. Алар арасында менә шундый искиткеч матур китап та бар иде. Төп үзенчәлеге – ул илһамландыра. Шуңа күрә бүгенге мастер-классымны да мин “Яңа биттән” дип атарга уйладым.

“Еш кына тормышымны яңа биттән башлыйм” дип әйтергә яраталар. Без бу фразаны тормышта да, әдәбиятта да очратабыз. Чөнки әдәбият тормыш белән бергә үрелеп бара. Тормыш, мәктәп турында сөйләшә башлаганбыз икән, үзеннән-үзе сорау туа: «Мәктәптә иң яраткан фәнегез нинди иде?»

(Химия, биология, математика)...Җавапларыгыз өчен рәхмәт.

Замана укучысына бу сорауны бирсәң, алардан да шундыйрак җавап ишетергә туры килер иде. Чөнки укучыга китап укып, аның эчтәлеген сөйләүгә кайтып калган әдәбият дәресләре инде кызык түгел. Ә 45 минут вакыт эчендә укытучы укучыга текстны һәрвакытта да тулы һәм аңлаешлы итеп җиткерә алмый. Без үзебез балалар дәресләребезгә теләп йөрерлек итеп укытырга тиеш. Ә баланың яңалыкны ачу шатлыгы, күбесенчә, укытучыдан тора.

Уку-укыту процессына яңа технологияләрне кертеп җибәрү бүген көн тәртибенә куелган мәсьәлә. Шуңа да, үземнең дәресләремдә теманы аңлаешлы һәм төпле үзләштерергә ярдәм итүче - квант технологиясен кулланам.

Квант методы универсаль, барлык өлкәләрдә дә эшли һәм гаҗәеп нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә.

Ул текст белән эшләгәндә гадәти рамкалардан чыгарга ярдәм итә һәм берничә позицияне үз эченә ала:

1)Беренчесе - төп (төп сүз, төшенчәләр, тезислар, схемалар яки таблица һәм сораулар)

2)Өстәмә (театр, поэзия). Эш тәртибе болай:

Материалабыз – текст.

Укучыларны дүрт төркемгә бүләбез:

- беренче төркем тексттан 10-15 төп сүзне аерып ала;
- икенче төркем схемасын ясый;
- өченче төркем сораулар әзерли;
- дүртенчесе эчтәлеген яза. Барлык укучылар да текстны укып, биремнәрне үтиләр.

Төркемдәге укучылар мөһим бер шартны истә тотарга тиеш: алар әзерләгән материал бу тексны укымаган һәм барлыгын да белмәгән кешегә дә аңлаешлы булырга тиеш. Аннан соң һәр төркем үз эшен презентацияли.

Әйдәгез бу метод белән эшләп карыйк.

Хөрмәтле коллегалар, Сезнең каршыгызда текст бирелгән, тик ул ак кәгазь бите белән капланган. Аны укыр алдыннан, кечкенә генә видеоролик карап китәрбез.

Видео (1 минут)

- Бу видео нәрсә турында?
- Ятимлек, балалар турында.
- Сез ятимлек турында нәрсә әйтә аласыз?
- Ятимлек ул - балачактан әти-әнисез, яклаучысыз-саклаучысыз калган балаларның ачы язмышы (башка вариантлар да булырга мөмкин).
- Димәк безнең текстыбыз нәрсә турында булачак?
- Балалар йорты, ятимлек турында.
- Дөрес, ятимлек турында.
- Текстны бер кат укып чыгабыз. Кайсыгыз укый? Рәхим итегез.

***Ятимлек***

Таң вакыты... Янсурның тәрәзәгә төбәлгән моңсу күзләре кояшның җылы нурлары белән очрашты. Күк йөзедәй мөлдерәмә тулы күзләр кемнедер көтә, кемнедер сагына... Кемне?! Үзенең газиз, яраткан, кадерле кешесе – әнисен. Ул ышана: аны әнисе кайчан да булса килеп алачак. Әйе, әйе, алачак! Аның да бит әнисенең йөрәк җылысын тоеп яшәргә хакы бар. Аны да әнисе иртән чәчләреннән сыйпап уятыр, тәмле коймаклары белән сыйлап чәйгә чакырып, йөзенә кагылыр, “Сабыем, уяндыңмы, җаным?” дип бар җылысын, назын биреп, кысып-кысып кочаклар. Янсур бу җылы кочакта эреп, бар күңеле белән әнисенең күкрәгенә сыеныр. Һәм үзен җир йөзендәге иң бәхетле бала итеп тояр... Әйе, әйе, ул ышана... Аның уйларын тәрбиячеләр тавышы бүлдерде: “Хәерле иртә, уянабыз, хәерле иртә!!!”.... Тик тәрәзә аша сузылып кергән кояш нурлары гына төне буена бер күз йоммаган нәни Янсурның чәчләреннән сыйпап, күз яшьләрен сөртә иде кебек... (Әхмәдиева Р.Р.)

Рәхмәт. Хәзер текст өстендә эшләүгә керешәбез. Бирем:

беренче төркем төп 15 сүзне язып ала;

икенче төркем схемасын төзи;

өченче төркем сораулар яза;

дүртенче төркемгә кыскача эчтәлекне язарга кирәк булачак. Эшкә керештек.

Эш барышында һәр төркем янына килеп, аларның гамәлләренә бәя биреп барам.

Эшне тәгәлләү.

Беренче төркем сүзләрне укый, икенче төркем схеманы яклыйлар, өченче төркем сораулар яза, дүртенче төркем шигырь яза.

- Рәхмәт, коллегалар.

Әңгәмә:

- Сез квант технологиясе турында беләидегезме?
- (Ишеткәнем бар, тик бу метод белән эшләп караган юк иде).
- Бу технология Сезгә ошадымы? Дәресләрегездә кулланачаксызмы?
- Үзенчәлекле. Бу технологияне дәрестә куллану кирәк дип саныйм.
- Сезнеңчә квант укучыларга нәрсә бирә? Ни өчен кирәк?

- Квант методы нәтиҗәгә эшли. Укучыны текстның нәкь мөһим өлешен аеып ала белергә өйрәтә.

- Фикерләрегез өчен бик зур рәхмәт. Сезнең белән килешми мөмкин түгел.

Шәм кабызу.

Хәзер миңа өч кеше кирәк булачак, менә Сез биргә килегез әле, зинһар.

Бирем: шәмнәрне кабызу.

(Беренчесе тиз кабыза, икенчесе акрынак, өченчесенең җебе шәмгә баткан була. Кабызалар).

Әңгәмә.

- Сезгә шәмне кабызу авыр булдымы?

- Юк, кыенлык тудырмады.
- Сез нәрсә әйтә аласыз?
- Җебе бераз кыскарак иде, ә тулаем алганда уңышлы булды.
- Сүз сезгә.
- Минем җебе шәмгә баткан иде, казып чыгарырга туры килде, вакытны алды, тик мин тырыштым һәм сез күрсәткән предмет ярдәм итте.
- Рәхмәт. Төркемнәрегезгә рәхим итегез.

Укучылар да бит төрле була:

- беренчесе үзенең дәрескә нигә килгәнен аңлый;
- икенчесе аңлый, тик мотивациясе җитми;
- өченчесен әле әзер түгел, аны кабызып, дөрләтеп җибәрергә кирәк. Без исә, укытучылар, әлегә шәмнәр кебек укучыларның белемнәрен бер дәрәҗәгә күтәрергә тырышырга тиешбез.

Минем мастер-классым “Яңа бит”тән дип аталды.

Барысы да яңа биттән башлана....Торшыгызның инде күп өлеше дәфтәргә язылган булуы мөһим түгел. Һәрбер яңа адым – язмыш китабының яңа бүлегенең исеме ул, ә аның авторы – Сез үзегез.

Шуңа Сезгә дә истәлеккә бәхетнең үзе кебек ак битле китапчыклар таратам. Сез дә анда матур-матур фикерләрегезне язып бара аласыз.

Китапчык тарату.

**_Ялалова Зульфия Фаеловна,_**
*учитель родного татарского языка и литературы первой квалификационной категории*
*МБОУ «Средняя общеобразовательная школа № 20»,*
*призер муниципального конкурса «Учитель года - 2021»*
*в номинации «Лучший учитель татарского языка»*



Зульфия Фаеловна имеет высшее педагогическое образование, окончила Казанский федеральный университет в 2015 году по специальности «Педагогическое образование», в 2017 году окончила магистратуру по специальности «Филология. Литературная критика и редактирование». Победитель конкурса на соискание гранта «Наш новый учитель» в 2016 году, победитель конкурса по присуждению Премии имени Клары Булатовой в номинации "Художественная литература", призер IX Республиканского конкурса молодых писателей "Иделем акчарлагы" в номинации "Проза". На уроках учителя царит творческая атмосфера. Отлично знает методику преподавания и воспитания, эффективно использует свои профессиональные знания на практике и в педагогической деятельности. Зульфия Фаеловна является руководителем школьного театра «Яшь йөрәкләр». Её ученики становятся победителями и призерами различных олимпиад и конкурсов, результативно участвуют в научно-практических конференциях различного уровня.

**Табигать бүләге.**

“Табигатьне сакларга, аның кадерен белеп яшәргә кирәк!”- дип әйтәләр, шулай эшләсәң генә табигать тә сиңа ярдәм кулы сузачак. Бу чыннан да хак, гаҗәеп сүзләр, ышанмаска мөмкин

дә түгел, чөнки ул һәрдаим кеше баласын, шаккаттыруын дәвам итә, үзенең шифасы белән дәвалый.

Мин кечкенә чакта, күрше кызы бик нык авырып китте. Ул минем якын дустым, без аның белән гел белән бер- беребездән аерылмый идек. Болыннарда чәчәк җыярга, урманга барып серле җирләр юлларга ярата идек, тик нишләптер аның аяклары авыртып, ул тәмам аякларына баса алмый торган булды, күпме генә йөреп тә, файдасы тимәгәч, шифаханә ягына да кул гына селтәделәр. Шулай итеп, әбисе аны үләннәр белән дәваларга тотынды, мин аңа бу эштә бик теләп ярдәм иттем.

Безнең авыл матур якта урнашкан, анда чишмәләр, адаштыргыч урманнар да, искиткеч җирләр дә күп, авылда оҗмах почмагы яшеренгән сыман иде! Мондагы горур таулар араларына алып, җәннәт бакчасына алып керә һәм, иң гаҗәбе шул, бу таулардан челтерәп- челтерәп шифалы чишмә ага... Язиләне дә без шул чишмәгә алып барырга булдык. Ни әйтсәң дә, карт-корылар тәҗрибәлерәк бит, алар яхшыны яманнан аера беләләр, дарулар белән дәваланганчы, үләннәр белән дәвала违налар иде.

Бу чишмәләр иленә аяк баскач та, әллә нинди сихри бер хис биләп алган, саф һавасыннан баш әйләнгән, бөтен борчуларың юкка чыккан, ә агып торган чишмәсеннән бер йотым су эчсәң, үзеңә чиксез дәва алган сыман буласың... Элек- электән үк бу чишмәләрне файдалы дип уйлаганнар, тик шифаханәләрдә дәвалану шартлары үзгәргәч, халык хәтерендә табигатьтән алып була торган дәвалар онытыла барган. Аларның да үзенең бер кагыйдәләре бар шул, Язиләнең әбисе бу табигать серләрен бик яхшы белә, кайсысы нидән файдалы икәнлеген яхшы аңлый иде, ул Язиләне тау арасыннан чыккан чишмә белән дәваларга тотынды, бу чишмәнең суы аеруча да салкын иде, аның суы белән юынгач аягыңны сөлгегә сөртергә ярамый икән, чишмә суы шулай аякны куырып алып, кайнарландырып дәвалый, ләкин шул салкын чишмәдә күпме генә юынсаң да, ни гаҗәптер салкын тими. Язиләгә дә күпме юынып та салкын тимәде һәм иң гаҗәбе шул ул атна- ун көн дигәндә аякларына басты, әллә нинди дарулар дәваламаган Язиләнең аякларын чишмә суы дәвалады! Шул көннән башлап без ул җирлекне “Шифа чишмәсе” дип атый башладык. Хәзер ул безнең өчен изге урын булып санала, халыкның яратып ял итә торган җире. Без анда ел саен килеп чәчәкләр утыртабыз, һәрдаим чистартып торабыз. Табигатьнең кадерен белеп яшибез!

***Ризванова Фануса Минигалиевна,***
*учитель родного языка и литературы первой квалификационной категории*
*МБОУ «Средняя общеобразовательная школа №29» НМР РТ,*
*лауреат муниципального конкурса «Учитель года - 2021»*
*в номинации «Лучший учитель татарского языка»*



С 2016 года Фануса Минигалиевна является руководителем школьного методического объединения учителей родного языка и литературы школы №29. Награждена Почетной грамотой Управления образования Исполнительного комитета НМР РТ и организации профсоюза работников образования в 2020 г.

За годы работы Ризванова Ф.М. зарекомендовала себя ответственным, трудолюбивым человеком. К обязанностям учителя относится добросовестно, постоянно работает над повышением своего профессионального уровня и педагогического мастерства. Ее ученики участвуют в различных интеллектуальных, творческих конкурсах, становятся победителями и призерами.

Фанусу Минигалиевну отличает творческий подход к любому делу. Она - кладезь интересных идей для уроков, мероприятий, творчества. Находится в постоянном поиске новых методов обучения, активно осваивает современные технологии, успешно применяя их в урочной и внеурочной деятельности. Педагог учитывает индивидуальные способности и возможности детей, возрастные и психологические особенности, уважает мир его интересов, учит мыслить, рассуждать, оценивать себя и других, уважать чужое мнение. Учащиеся на уроках активны, включены в работу, так как педагог умеет создать на уроке хороший психологический климат.

Самым главным в своей работе она считает привитие учащимся художественного вкуса, интереса и любви к родному языку, умения ценить его величие и богатство.

Фануса Минигалиевна - человек с неиссякаемой энергией, которого хватает на всех: и на детей, и на родителей. Дети и родители отвечают ей любовью и уважением.

**Сыйныфтан тыш чара.**
**“Тамчы шоу” Интеллектуаль күңел ачу бәйгесе.**

**Чараның максаты һәм бурычлары:**

-укучыларда Татарстанда яшәүче халыкларның телләренә, гореф-гадәтләренә, кызыксыну, хөрмәт уяту;

- Туган ил белән горурлану, туган җиргә мәхәббәт хисләре тәрбияләү.
- укучыларның сөйләм телен, дөньяны танып- белү, күзаллауларын арттыру, баету;
- башка милләт вәкилләренә карата хөрмәт, дуслык хисләре тәрбияләү

**Җиһазлау:**

- компьютер, проектор, презентация, сандык, милли киемнәрдәге курчаклар.

**Бәйгенең барышы**

**Алып баручы:**

- Исәнмесез укучылар, укытучылар һәм килгән кунаклар!

Без бүген сезнең белән **«Тамчы шоу» интеллектуаль уенынына** җыелдык. Ни өчен тамчы соң дисәгез, халык : “Тамчыдан күл җыела” яки “Тамчы тама – тама ташны тишә”, ди. Без дә белемне шулай берәмтекләп, тамчылап җыябыз да гыйлемле кешегә әйләнәбез.

-Без яңа 2021 нче елга аяк бастык. Ә 2021 нче Татарстан республикасында нинди ел дип игълан ителде.? (Татарстанда туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы.)

- Әйе, дөрес. 2021 нче ел Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов тарафыннан туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителде.

